КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 май

г.Казань

№ 406

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль-хезмәт өлкәсе мониторингы турында» 2010 ел, 31 март, 205 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының социаль-хезмәт өлкәсе мониторингы турында» 2010 ел, 31 март, 205 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 21 декабрь, 1046 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче пунктта «мәгълүматлар кертү» сүзләрен «мәгълүматлар урнаштыру (кертү)» сүзләренә алыштырырга;

2 – 4 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасының Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Регламент нигезендә «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасында (алга таба – Система) мәгълүмат урнаштырырга.

3. Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы «Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасына, Татарстан

Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән социаль-хезмәт өлкәсе мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлек турындагы килешүләргә таянып, Регламент нигезендә Системада мәгълүмат урнаштыруны тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

Регламент нигезендә Системада җыелма хисапларны бастырып чыгару юлы белән Татарстан Республикасының социаль-хезмәт өлкәсе мониторингын (алга таба – мониторинг);

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең җаваплы органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасы тарафыннан мәгълүматны Системада үз вакытында урнаштыруны тикшерүдә тотуны;

Системаның тиешле функционаллары ярдәмендә мониторингны һәм визуальләштерүне актуаль хәлдә тотуны;

Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы «Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасы белән социаль-хезмәт өлкәсе мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешүләр төзүне.»;

түбәндәге эчтәлекле $5^1$ нче пункт өстәргә:

«$5^1$. «Татарстан Республикасының Мәгълүмат технологияләре үзәге» дәүләт унитар предприятиесенә Системада мониторингны техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашырырга.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының социаль-хезмәт өлкәсе мониторингы өчен мәгълүматлар кертү регламентын (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2010 ел, 31 март, 205 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 20 май, 406 нчы
карары редакциясендә)

# Татарстан Республикасының социаль-хезмәт өлкәсе мониторингы өчен мәгълүматлар урнаштыру (кертү) РЕГЛАМЕНТЫ

1. Бу Регламент белән Татарстан Республикасының социаль-хезмәт өлкәсе мониторингы өчен мәгълүматлар составы, аларны кертү тәртибе һәм вакытлары, мәгълүматларны кертү өчен җаваплы органнар һәм оешмалар билгеләнә.

2. Мониторингны гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат урнаштыручы (кертүче) мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар:

Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары;

федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары;

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасы.

Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасы Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты белән төзелгән социаль-хезмәт өлкәсе мәсьәләләре буенча мәгълүмати хезмәттәшлек турындагы килешүләр (алга таба – килешү) нигезендә мониторингны гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат урнаштыра (кертә).

3. Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары «Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылык системасында (алга таба – Система) мониторингны гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат урнаштыра.

«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасы мониторингны гамәлгә ашыру өчен мәгълүматны Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетына килешү белән билгеләнгән форма буенча кертә.

4. Мониторингны гамәлгә ашыру өчен мәгълүмат бу Регламентка теркәлгән 1 – 5 нче кушымталарында күрсәтелгән исемлек, эзлеклелек һәм вакытлар нигезендә мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучылар тарафыннан урнаштырыла (кертелә).

5. Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты Системада мониторинг нәтиҗәләре буенча түбәндәге җыелма хисапларны бастырып чыгаруны гамәлгә ашыра:

ай саен урнаштырыла (кертелә) торган мәгълүмат буенча – хисап аеннан соң килүче айның 18 енә кадәр;

квартал саен урнаштырыла (кертелә) торган мәгълүмат буенча – I, II, III кварталлар өчен хисап кварталыннан соң килүче өченче айның 30 ына кадәр; IV квартал өчен хисап кварталыннан соң килүче дүртенче айның 30 ына кадәр;

ел саен урнаштырыла (кертелә) торган мәгълүмат буенча – хисап елыннан соң килүче елның 31 декабренә кадәр.

6. Мониторингны гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты тарафыннан төзелә торган мәгълүмат ресурсы мәгълүматлары кулланыла.

7. Мониторингны гамәлгә ашыру өчен урнаштырыла (кертелә) торган мәгълүматның тулылыгы, актуальлеге һәм дөреслеге өчен Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасы җитәкчеләре җавап бирә.